Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №VII-7**

Балык Бистәсе штп 2026 елның 17марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 31.08.2021 ел, №XI-3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 29.12.2025 №548-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 31.08.2021 ел, №XI-3 карары (05.03.2022 №XX-6; 25.05.2023 №XXXVIII-6; 07.05.2025 №LVIII-8 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.9.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.9.5. Әгәр контрольдә тотыла торган зат өчен үз-үзен җайга сала торган оешмада мәҗбүри әгъза булу каралган булса, контрольдә тотыла торган затлар, аларның вәкилләре - контроль чаралар уздырганда (контроль чаралар үткәрелгәндә контроль органнарның контрольдә тотыла торган затлар белән хезмәттәшлеге таләп ителми торган контроль чаралардан тыш) һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, контроль чаралар уздырганда кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы вәкаләтле вәкил булуга каршылык тудырмаска.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башлыгы Р.Р. Ислямов